СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2021 № 15/11

На № ___________ от _______________

# КАРАР

**2022 елга Тукай муниципаль районы Советының эш планы турында**

Тукай муниципаль районы уставының 29 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елга Тукай муниципаль районы Советының эш планын расларга (кушымта нигезендә).
2. Муниципаль район Советының даими комиссияләренә, Башкарма комитетка Совет каравына кертелә торган мәсьәләләрне әзерләүгә зур игътибар бирергә, Советның, аның органнарының һәм үз норматив-хокукый актларының үтәлешенә ныклы контрольне гамәлгә ашырырга.
3. Билгеләнгән чаралар үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлегенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев

2021 елның 14 декабрендә 15/11 номерлы Тукай муниципаль районы Советы карары белән расланган

# 2022 елга Тукай муниципаль районы Советы эш планы

| | | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Оештыру мәсьәләләре** | | | |
| 1. | Муниципаль район Советы утырышларын үткәрү | Ике айга кимендә 1 тапкыр | Муниципаль район Башлыгы урынбасары |
| 2. | Даими комиссияләр эшен оештыру | Кварталга кимендә 1 тапкыр | Совет аппаратының оештыру бүлеге |
| 3. | Югары органнарның кабул ителгән карарлары һәм үз карарлары үтәлешен контрольдә тоту | Бөтен чорда | Совет аппаратының оештыру бүлеге |
| 4. | Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен, хатларын һәм шикаятьләрен карап тикшерүгә аерым игътибар бирергә. Аларның барлыкка килү сәбәпләрен бетерү буенча чаралар күрү | Системалы рәвештә | Муниципаль районның җирле үзидарә органнары |
| 5. | Елга 1 тапкыр Тукай муниципаль районы уставы һәм «Тукай муниципаль районы Советы депутаты статусы турында» нигезләмә нигезендә сайлаучылар алдында депутатларның хисапларын оештыру | I яртыеллык | Совет аппаратының оештыру бүлеге, авыл җирлекләре Советлары |
| 6. | Район Советы депутатлары тарафыннан халыкны кабул итү | Һәр айның соңгы шимбәсе | Район Советы аппаратының оештыру бүлеге |
| 7. | Авыл җирлекләре Советлары эшен оештыруда методик ярдәм күрсәтү | Бөтен чорда | Район Советы аппараты һәм Башкарма комитеты бүлекләре |

## <u>Совет каравына кертелә торган мәсьәләләр</u>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Тукай муниципаль районында икътисад һәм социаль өлкә тармакларын цифрлы трансформацияләү барышы турында | Январь | Район Башкарма комитеты |
| 2. | 2021 елда эш нәтиҗәләре һәм 2022 елга бурычлар турында район Башлыгы хисабы | Февраль | Район Башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | 2021 елның январь-февраль айларында Тукай муниципаль районы авыл җирлекләрендәге җыелышларда әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча «юл картасы»ның үтәлеше турында | Март | Район Башкарма комитеты |
| 4. | 2021 елда авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча эш нәтиҗәләре һәм 2022 елга бурычлар турында | Март | Район Башкарма комитеты, районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) |
| 5. | 2021 ел өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге эшчәнлеге турында хисап | Март | Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районындагы бүлеге (килешү буенча) |
| 6. | 2021 елда Татарстан Республикасында һәм Тукай муниципаль районы территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында | Апрель | Тукай муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил |
| 7. | 2021 ел өчен «Тукай муниципаль районы контроль-хисап палатасы» МКУ эшчәнлеге турында хисап | Апрель | «Тукай муниципаль районы контроль-хисап палатасы» МКУ |
| 8. | 2021 ел өчен район бюджеты үтәлеше турында хисап | Апрель | Финанс-бюджет палатасы |
| 9. | Балалар һәм яшүсмерләрнең җәйге ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында | Апрель | Район Башкарма комитеты |
| 10. | Район халкының сәламәтлеген ныгыту буенча күрелә торган чаралар турында | Апрель | Район Башкарма комитеты, «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 11. | Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы законнарны үтәү буенча эшнең торышы турында | Май | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе |
| 12. | Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында | Май | Районда этно-конфессиональ, миграция һәм иҗтимагый-сәяси вәзгыять буенча эшче төркем |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Район территориясендә яшь буынга гражданлык һәм патриотик тәрбия бирү турында | Май | Район Башкарма комитеты |
| 14. | 2022 елның I яртыеллыгына районның социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре турында | Август | Район Башкарма комитеты |
| 15. | Тукай муниципаль районында икътисад һәм социаль өлкә тармакларын цифрлы трансформацияләү барышы турында | Август | Район Башкарма комитеты |
| 16. | 2022 елның I яртыеллыгына район бюджеты үтәлеше турында | Август | Финанс-бюджет палатасы |
| 17. | Тукай муниципаль районы территориясендә илкүләм проектларны тормышка ашыруның барышы турында | Октябрь | Район Башкарма комитеты |
| 18. | Тукай муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү программасын гамәлгә ашыру турында | Октябрь | Район Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |
| 19. | Тукай муниципаль районында ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүләренә ярдәм итү турында | Ноябрь | Район Башкарма комитеты, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча) |
| 20. | «2021-2024елга Тукай муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа» үтәлеше турында | Ноябрь | Район Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |
| 21. | Тукай муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү торышы турында | Ноябрь | Район Башкарма комитеты |
| 22. | 2022 елның январь-сентябрь айларына Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш йомгаклары турында, елның көтелгән нәтиҗәләре һәм 2023-2025 | Декабрь | Район Башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | елларга социаль-икътисадый үсеш фаразы | | |
| 23. | 2023 елга Тукай муниципаль районы бюджеты турында | Декабрь | Район Башкарма комитеты |